КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 декабрь г.Казань № 1211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 841 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 841 нче карарына, беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2022 елга Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 10 756 сум, эшкә яраклы халык өчен – 11 724 сум, пенсионерлар өчен – 9 250 сум, балалар өчен – 10 433 сум итеп расларга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин